Республика Татарстан

Совет Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы
Советы

КАРАР

КАРАР

30 март 2022 ел Менделеевск ш. №111

Менделеевск шәһәрендә
оешмаларның сезонлы стационар
булмаган сәүдә объектларын
урнаштыру хокукына түләүдән
азат итү һәм кичектерү буенча
кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына
ярдәм чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы күрсәтмәсе һәм Россия Федерациясендә килеп туган икътисадый хәлгә бәйле рәвештә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Менделеевск шәһәрендә ташламалар кертергә һәм стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукына 2022 елның 1 апреленнән 2022 елның 30 июненә кадәр түләүдән азат итәргә (салкын, алкогольсез эчемлекләр, баллы мамык нокталары, спорт инвентаре прокаты нокталары, җәйге кафелар урнаштыру өчен билгеләнгән вакытлы корылмалар)

2. Менделеевск шәһәрендә ташламалар кертергә һәм стационар булмаган сәүдә объектларын җәйге кафелар урнаштыру өчен билгеләнгән оешмаларга (салкын, алкогольсез эчемлекләр, баллы мамык нокталары, спорт инвентаре прокаты нокталары, җәйге кафелар урнаштыру өчен билгеләнгән вакытлы корылмалар) урнаштыру хокукына түләүне 2022 елның 1 июненән 2022 елның 1 октябренә кадәр кичектереп торырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары Л.К.Галиева